ГЛАВА АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.05.2020 п.г.т.Алексеевское № 55

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында дәүләт һәм ведомство, муниципаль бүләкләр белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибен раслау хакында» Алексеевск муниципаль районы башлыгының 2018 елның 28 декабрендәге 114 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 10 мартындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, шулай ук 2020 елның 30 апрелендәге коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча, коррупциоген факторларны бетерү максатларында, туры китерү максатларында

**карар кылам**:

1. Алексеевск муниципаль районы башлыгының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында дәүләт һәм ведомство, муниципаль бүләкләр белән бүләкләү турында үтенечнамәләрне карау тәртибен раслау хакында» 2018 елның 28 ноябрендәге 114 номерлы карарына 1 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле үзгәреш кертергә:

«Чурин Николай Петрович — Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары (килешү буенча)»

сүзләрен түбәндәге сүзләр белән алмаштырырга:

«Симашева Альбина Валентиновна — Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары (килешү буенча)».

2. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында дәүләт һәм ведомство, муниципаль бүләкләр белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибен раслау хакында» 2018 елның 28 ноябрендәге 114 номерлы Алексеевск муниципаль районы башлыгының карарына 2 нче кушымтада

- 4 абз. 2.1 п. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бүләкләү материалларын комиссия утырышына әзерләү һәм беркетмәне рәсмиләштерү комиссия утырышы көненнән алып 3 көн эчендә комиссия секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла»;

- 2 абз. 2.2 п. Түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Комиссия карары комиссия рәисе (ул булмаганда - комиссия рәисе урынбасары), шулай ук утырышны уздыру көнендә секретарь тарафыннан имзалана торган бәяләү кәгазе белән рәсмиләштерелә»;

- 3.1 п. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеген, җирле үзидарә органы коллективын «Татарстан Республикасы Президенты Рәхмәте» дәүләт бүләгенә тапшыру өчен кирәкле документлар пакеты төзи.

3. Алексеевск муниципаль районы башлыгының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында дәүләт һәм ведомство, муниципаль бүләкләр белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибен раслау хакында» 2018 елның 28 ноябрендәге 114 номерлы карарына 3 нче кушымтада:

- 1 пп. 8 п. «гражданның яисә оешманың» сүзләрен «гражданның, муниципаль берәмлекнең яисә оешманың» сүзләренә, «гражданнарга яисә оешмаларга» сүзләрен «гражданнарга, муниципаль берәмлекләргә яисә оешмаларга» сүзләренә алмаштырырга;

- 8.1 п. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.1. Бүләкләү турындагы документларны карау һәм бүләкләү йомгаклары буенча комиссия утырышын бәяләү кәгазе район башлыгына комиссия утырышын үткәргән көннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча җибәрелә».

4. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмәтның рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы** **С.А. Демидов**